ГЛАВА МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

_20.11.2020 с. Майдан № 4

Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябреннән , № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020нче елның 4нче декабрендә 11 сәгать 30 минутта Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020нче елның 4нче декабрендә сәгать 13: 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020нче елның 5нче декабрендә сәгать 9: 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2020нче елның 5нче декабрендә сәгать 10: 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2020нче елның 5нче декабрендә сәгать 11: 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.
6. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

   1 этап: Мәйдан авылы, Яшьләр урамында яшәүчеләр;
   2 этап: Мәйдан авылы, Беренче Май урамында яшәүчеләр;
   3 этап: Мәйдан авылы, Кооператив урамында яшәүчеләр;
   4 этап: Мәйдан авылы, Яңа урам, Киров урамында яшәүчеләр;
   6 этап: Мәйдан авылы, Совет урамында яшәүчеләр.

7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме?:

- товар белән тәэмин итүче исәп - хисап пунктына кадәр китереп, Мәйдан авылына юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

8. Халык җыеннарын үткәрергә:
   1 этап: Мәйдан авылы, Молодежная урамы, 7нче номерлы йорт янында
   2 этап: Мәйдан авылы, Беренче Май урамы, 12 нче йорт янында
   3 этап: Мәйдан авылы Кооператив урамы буенча 21А йорты янында
   4 этап: Мәйдан авылы, Киров урамы буенча 92нче йорт янында
   5 этап: Мәйдан авылы, Совет урамы, 45нче йорт янында мәйдан

9. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев